Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Янил авыл җирлеге Башлыгы

КАРАРЫ

13.11.2023 ел №7

«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Янил авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

2. 2023 елның 25 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

3. 2023 елның 25 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Янил авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Янил авылы, Мәктәп урамы, 18 адресында урнашкан Янил авыл мәдәният йорты бинасында уздырырга.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Янил авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә житкән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Янил авылының Үзәк урам юлларына вак таш җәю (ком һәм вак таш сатып алу, ташу, җәю), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

2) Янил авылында урам юл челтәрен карап тоту, юл билгеләре сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү;

3) Янил авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау;

4) йорт төзү, урнаштыру, ремонтлау, Янил авылында күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (килешү буенча эш өчен түләү), проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын төзү

6) Янил авылы Үзәк урамында су белән тәэмин итү системасын төзү, проект-смета документациясен төзү

7) Янил авылы Үзәк урамында тротуарларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен төзү;

8) массакүләм ял итү урыннарын чүп-чар урналары белән җиһазландыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Янил авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов

ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893